**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы карары**

Балтач авылы № **168** **19** май **2020** ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» **2003** елның **6** октябрендәге **131**-ФЗ номерлы Федераль законның **14** статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Балтач авыл җирлеге Советы карар итте:

**1.** Кушымта итеп бирелгән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын (**24.10.2012 №44 ,20.10.2013 № 62, 18.02.2014 №72, 16.07.2014 №89, 26.08.2017 №58, 13.11.2018 №115** карарлар редакциясендә) хупларга (**1** нче кушымта).

**2.** Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының **24.10.2012 №44 ,20.10.2013 № 62, 18.02.2014 №72, 16.07.2014 №89, 26.08.2017 №58, 13.11.2018 №115** карарлар белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

**3.** Билгеләргә:

- уздыру вакыты – **2020** елның **28** маеннан **2020** елның **30** июненә кадәр;
- үткәрү урыны – Балтач авылы, Яшьләр урамы, **1** а йорт;
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр **2020** елның **30** июненә кадәр- Балтач авылы, Яшьләр урамы, **1**А йорт, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетына (эш көннәрендә **8.00** сәгатьтән **17.00** сәгатькә кадәр төшке ашка **12.00** сәгатьтән **13.00** сәгатькә кадәр тәнәфес) кертелә ала.

**4.** Халык тыңлаулары үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

-Хәбипов Л.Л. – Балтач авыл җирлеге башлыгы;

-Ахунов Р.Т. –Балтач авыл җирлеге Советының № **5** округ депутаты;

-Яркаев А.А. – Балтач авыл җирлеге Советының №**2** округ депутаты;

**5.** Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының **24.10.2012 №44 ,20.10.2013 № 62, 18.02.2014 №72, 16.07.2014 №89, 26.08.2017 №58, 13.11.2018 №115** карарлар белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча эшче группага ачык тыңлаулар уздыруны, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

**6.** Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә.

**7.** Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: **http://pravo.tatarstan.ru** һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: **http//aznakayevo.tatar.ru**. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән, **2020** елның **25** маеннан да соңга калмыйча халыкка җиткерергә.

**8.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Балтач авыл Советының
**2020** елның **19** маендагы
**168** номерлы карарына **1**
нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы карары**

Балтач авылы №___ __ ______ **2020** ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советы карары белән расланган **2012** елның 24.10. 44 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (**2013** елның 20.10. 62 номерлы, **2014** елның 18.02. 72 номерлы, **2014** елның 16.07. 89 номерлы, **2017** елның 26.08.58 номерлы, **2018** елның 13.11.№ 115 номерлы карарлар редакциясендә)

**2004** елның **28** июлендәге **45-**ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Балтач авыл җирлеге Советы карар итте:

**1.** Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советы карары белән расланган **2012** елның 24.10. 44 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (**2013** елның 20.10 .62 номерлы, **2014** елның18.02. 72 номерлы, **2014** елның 16.07.

89 номерлы, **2017** елның 26.08. 58 номерлы, **2018** елның 13.11.115 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 2.11.13** пунктта:

а) «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

б) «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

**1.2. 2.11.16** пунктта «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

**1.3.** Түбәндәге эчтәлекле **2.11.18** пункт белән тулыландырырга:

«**2.11.18.** Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

**2.** Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: **http://pravo.tatarstan.ru** һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: **http//aznakayevo.tatar.ru**. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.